| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СУГУШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«СУГЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2025 елның 10 гыйнвары №1

«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Сугышлы авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 29.12.2004 елгы 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28, 5.1 статьясы, « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Сугышлы авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (алга таба - Проект).

2. Гавами тыңлаулар уздыруга вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны уздыру вакытын – Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узэк урамы, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре»бүлегендә әлеге карар басылып чыккан көннән алып гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастырып чыгарган көнгә кадәр кимендә 1 ай һәм 3 айдан да артмаска тиеш дип билгеләргә.

4. Проекта фикер алышу буенча гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздыруны 2025 елның 22 гыйнварында 16.30 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узэк урамы, 27 йорт.

5. Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

5.1. Проект һәм аңа мәгълүмат материалларын Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә 2025 елның 17 гыйнварында урнаштыру ;

5.2. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар экспозициясен ачу һәм үткәрү (алга таба - экспозиция) 10.01.2025 дән 20.01.2025 кә кадәр (ял көннәреннән тыш). Чәршәмбе, җомга, эш сәгатьләре: 14.00 сәгатьтән 16.00

сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узэк урамы, 27 йорт  йорт адресы буенча;

5.3. Экспозициягә килүчеләргә консультация 10.01.2025 дән 20.01.2025 (ял көннәреннән тыш). Чәршәмбе, җомга, эш сәгатьләре: 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узэк урамы, 27 йорт  адресы буенча;

5.4. гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;

5.5 гавами тыңлаулар беркетмәсен рәсмиләштерү, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында имзаларны әзерләү һәм бастырып чыгару Сугышлы авылы, Узэк урамы, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре»бүлегендә урнаштыру.

5.6 Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларны дәлилләнгән нигезләүне дә кертеп, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре»  бүлегендә һәм «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы»  федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Гавами тыңлауларда катнашучылардан Проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителә дип билгеләргә:

гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын уздыру барышында язмача (әлеге карарга кушымта нигезендә) яисә телдән;

язмача (әлеге карарга кушымта нигезендә) Лениногорск муниципаль районының «Иске Куак  авыл җирлеге» башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узэк урамы, 27 йорт;

әлеге карарның 5.2 пунктында күрсәтелгән вакытларда экспозиция уздыру чорында проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) язу юлы белән.

7. Гавами тыңлауларда катнашучыларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси белешмәләр турында» Федераль законда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

8. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты проектын карау буенча гавами тыңлаулар әзерләү һәм уздыру өчен җаваплыны билгеләргә.

9.Әлеге карарны түбәндәге адрес : Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узэк урамы, 27 йорт буенча  урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткеререгә Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре»  бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru)  бастырып чыгарырга.

10. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам

Лениногорск муниципаль районы
« Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

А.П. Зыатдинова